| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2023 г. Казань № 741-123/кс-2023

Алабуга муниципаль районы «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен 2024-2026 елларга эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.12.2023 №59-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Алабуга муниципаль районы «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ) өчен әлеге карарның 1-2 нче кушымталарына туры китереп, эчәргә яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар;

әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә 2024-2026 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ өчен эчәргә яраклы суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын.

2. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисад зонасы» АҖ ирекле файдаланылырга

тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 741-123/кс-2023
карарына 1 нче кушымта

2024 елга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ өчен
эчәргә яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Чор | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Алабуга муниципаль районы | | |
| 1 | «Алабуга» СҖТ МИЗ» АҖ | | |
| | | | |
| 1.1 | халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 46,68 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 53,77 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 38,90 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 44,81 |

* Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2023 № 741-123/кс-2023
карарына 2 нче кушымта

2025-2026 елларга* салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Алабуга» СЖТ МИЗ» АҖ өчен эчәргә яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Чор | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Алабуга муниципаль районы | | |
| 1 | «Алабуга» СЖТ МИЗ» АҖ | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)** | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 53,36 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 53,36 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 53,36 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 55,96 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар НДС исәбеннән башка күрсәтелгән) | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 44,47 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 44,47 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 44,47 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 46,63 |

* 2025-2026 елларга эчәргә яраклы суга тарифларга ел саен төзәтмәләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә уздырыла.
** Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2023 № 741-123/кс-2023 карарына 3 нче кушымта

## 2024-2026 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Алабуга» СЖТ МИЗ» АЖ өчен эчәргә яраклы суга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе* | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе** | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Алабуга» СЖТ МИЗ» АЖ | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | 2024 | 216 116,52 | - | - | 12,86 | 1,05 |
| | | 2025 | - | 1 | - | 12,86 | 1,05 |
| | | 2026 | - | 1 | - | 12,86 | 1,05 |

* Озак сроклы җайга салуның икенче һәм аннан соңгы елларына операция чыгымнарының база дәрәҗәсе Россия ФТХ 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 45 пунктында каралган формула буенча исәпләнә.
** «Алабуга» СЖТ МИЗ» АЖ өчен норматив табыш дәрәҗәсе билгеләнми.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге